**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**
422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**
422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2019ел №183

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе турындагы Нигезләмәнең үз көчен югалтуын тану хакында

«Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында " 2005 елның 30 декабрендәге 143-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә», «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе турында «2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 24 сентябрендәге 798 номерлы карары белән Татарстан Республикасының Әтнә муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә район Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясенең «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе турында»2018 елның 12 ноябрендәге 123 номерлы карарының 3 пункты белән расланган нигезләмәсен үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә түбәндәге адрес буенча игълан итәргә: http://atnya.tatarstan.ru.

Әтнә муниципаль район башлыгы-

Район Советы рәисе Г. Г. Хәкимов